**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

тугызынчы утырыш
# КАРАРЫ

15 нче май 2026 ел **№ 41** Теләче ав.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның
тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә
багышланган чаралар турында

Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 26 декабрендәге 1089 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2026 елның 17 мартындагы 601-VII ДС номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы Д.С. Иксановның, МКУ «ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» методисты Г.М. Сәхәбиеваның “Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чаралар турында” докладларын тыңлап, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. “Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чаралар турында” мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә һәм МКУ «ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нә шагыйрьнең 140 еллыгы уңаеннан планлаштырылган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм районның җирле халкын җәлеп итеп киң яктыртырга, Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча республика планын гамәлгә ашыруда актив катнашырга.
3. Җирле үзидарә органнары, учреждениеләр җитәкчеләренә ел дәвамында хезмәт коллективларының, шул исәптән педагогларның, китапханәчеләрнең, мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең, Габдулла Тукай тормышына һәм иҗатына багышланган күргәзмә һәм мәгърифәтчелек проектларына баруларын оештырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Теләче муниципаль
район Башлыгы А.Г. Фатхуллин